КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 декабрь г.Казань № 1163

2026 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген расларга.

2. 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип таныргa:

«2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2024 ел, 20 декабрь, 1172 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 20 декабрь, 1172 нче карары белән расланган 2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле

инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 ел, 27 март, 174 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 26 декабрь, 1163 нче
карары белән расланды

2026 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге

I. Өстенлекле инвестиция проектлары:

1. Авыл хуҗалыгы һәм балык үрчетү:

1) «Татарстан Республикасы Сарман районында урнашкан, 4 000 башка исәпләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексын төзү» («Сарман» агрофирмасы» ҖЧҖ, Сарман муниципаль районы);

2) «Чаллы элеваторы» АҖенең элеватор куәтләрен реконструкцияләү – һәрберсе сәгатенә 100 план тоннага исәпләнгән ике киптерү җайланмасы белән 60 000 тоннага ашлык саклау куәтләрен төзү» («Чаллы элеваторы» АҖ, Яр Чаллы шәһәре);

3) «Чаллы элеваторы» АҖенең элеватор куәтләрен реконструкцияләү – элеваторның капчык бүлеге һәм силос корпусы булган эш манарасын реконструкцияләү» («Чаллы элеваторы» АҖ, Яр Чаллы шәһәре);

4) «Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлегендә мөгезле эре терлекнең 3 000 фураж баш санына исәпләнгән сөт-товар комплексын төзү» («Камский бекон» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

5) «Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлегендә сөт токымындагы 6 400 башка исәпләнгән мөгезле эре яшь терлекләр үстерү һәм симертү буенча махсуслаштырылган ферма төзү» («Камский бекон» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

6) «Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Коноваловка авыл җирлеге» адресы буенча катнаш азык цехы белән азык үзәген төзү» («Камский бекон» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

7) «Мөгезле эре терлекнең 10 000 фураж башына исәпләнгән сөт-товар комплексын төзү» («Камский бекон» ҖЧҖ, Мөслим муниципаль районы);

8) «Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Богодаровка торак пункты янында 12500 баш ана дуңгызга исәпләнгән дуңгыз комплексын төзү» («Камский бекон» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

9) «Бөгелмә муниципаль районында 120 мең тоннага кадәр бер тапкыр саклау күләме белән бөртекле һәм майлы культураларны саклау өчен элеватор төзү» («Август-Лениногорск» ҖЧҖ, Бөгелмә шәһәре);

10) «Татарстан Республикасы Кайбыч районының Ульянково авылы янында 3 400 сыерга исәпләнгән сөт-товар фермасын төзү» («Август-Кайбыч» ҖЧҖ, Кайбыч муниципаль районы);

11) «Елына 6100 тонна ит бирә торган сәнәгать күләмнәрендә куяннар үстерү буенча терлекчелек комплексын төзү» («КАСТЕЛЛУМ» ҖЧҖ, Чүпрәле муниципаль районы);

12) «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Тавәле авылы янында 10 500 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексы» («Милк Ингредиентс» ҖЧҖ, Мамадыш муниципаль районы);

13) «Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авылында мөгезле эре терлекләрнең 3 000 баш савым сыерына исәпләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексы» («Шахтер» ҖЧҖ, Әтнә муниципаль районы);

14) «Әтнә муниципаль районының Кышлау авылында мөгезле эре терлекләрнең 3 000 савым сыерына исәпләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексы» («Таң» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы, Әтнә муниципаль районы);

15) «Татарстан Республикасы Теләче районының Балыклы авылы янында урнашкан мөгезле эре терлекнең 1 000 баш савым сыерына исәпләнгән сөт-товар фермасын төзү» («Алан» АҖ, Теләче муниципаль районы);

16) «Яшелчә, җиләк-җимеш, җиләкләрне саклау, эшкәртү, сатуга әзерләү, шоклы туңдыру һәм аларны сату буенча комплекслы предприятие булдыру» («ТАКПО» ҖЧҖ, Әлмәт шәһәре);

17) «Татарстан Республикасы Кукмара районының Тырыш авылы янында урнашкан савым сыерлары өчен 1 006 терлек урынына исәпләнгән сөт-товар фермасы» («Вахитов» ҖЧҖ, Кукмара муниципаль районы);

18) «Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Шуран авылы адресы буенча урнашкан 6000 тоннага яшелчә саклагыч төзү» («Шураны Эко гарден» авыл хуҗалыгы кулланучылар эшкәртү тәэмин итү-сату кооперативы, Лаеш муниципаль районы);

19) «Шураны Эко Гарден» яшелчә культуралары өчен селекция-орлыкчылык үзәге («ШУРАНЫ ЭКО ГАРДЕН»ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

20) «500 мең тонна куәт белән ашлыкны тирәнтен эшкәртү» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы).

2. Азык-төлек продуктлары җитештерү:

1) «Сыр ясый торган сөт комбинатын төзү» («Кукмара сөт комбинаты» ҖЧҖ, Кукмара муниципаль районы);

2) «Казан сөт комбинатында җитештерүне модернизацияләү, киңәйтү» («Казан сөт комбинаты» ҖЧҖ, Казан шәһәре).

3. Химия производствосы:

1) «Аммиак һәм карбамид җитештерү комплексын төзү (Аммиак һәм карбамид җитештерү комплексы («Аммоний 2» ҖЧҖ)), Менделеевск шәһәре, Татарстан Республикасы, Россия» («Аммоний 2» ҖЧҖ, Менделеевск шәһәре);

2) «Нәфис Косметикс» АҖндә көнкүреш химиясе һәм техник продукция җитештерүне киңәйтү һәм техник яңарту» («Нәфис Косметикс» АҖ, Казан шәһәре);

3) «Суда эри торган пленкалар җитештерүне оештыру» («Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

4) «Казаньоргсинтез» ГАҖ чикләрендә урнашкан полиолефиннар өчен

катализатор фабрикасы. Силикагельдә хром катализаторлары җитештерү» («Казаньоргсинтез» ГАҖ, Казан шәһәре);

5) «50 мең тонна куәт белән гексен-1 җитештерү буенча сәнәгать җайланмасын төзү» («Казаньоргсинтез» ГАҖ, Казан шәһәре);

6) «Этилен буенча елына 600 мең тонна куәт белән олефиннар җитештерү буенча яңа комплекс төзү» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, Түбән Кама шәһәре);

7) «Татарстан Республикасында биогаз җитештерү тармагын булдыру («Энерготех» фәнни-җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ, Менделеевск муниципаль районы);

8) «Экструдланган пенополистирол җитештерү буенча җитештерү комплексы булдыру («ГРАФИТ» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы).

4. Металл булмаган башка минераль продуктлар җитештерү:

«Гомуми файдаланудагы юллар салу өчен асфальт-бетон катнашмасы әзерләү производствосы» («Галеон» ҖЧҖ, Биектау муниципаль районы).

5. Машиналар һәм җиһазлар җитештерү:

1) «Автоматлаштырылган тапшырулар тартмасын эшләү һәм индустриализацияләү» («ЦФ Кама» ҖЧҖ, Яр Чаллы шәһәре);

2) «Роботлаштырылган тапшырулар тартмасын эшләү һәм индустриализацияләү» («ЦФ Кама» ҖЧҖ, Яр Чаллы шәһәре).

6. Транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү:

1) Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, «Казан вертолет заводы» АҖ базасында «Казан вертолет заводы» АҖнең «Россия вертолетлары» холдингының композит җитештерү үзәген оештыру («Казан вертолет заводы» АҖ, Казан шәһәре);

2) «Татарстан Республикасында 80 ат көченнән 212 ат көченә кадәр куәтле тракторларның сәнәгать җитештерүен булдыру» («МТЗ-Татарстан сәүдә-җитештерү компаниясе» ҖЧҖ, Алабуга муниципаль районы).

7. Электр энергиясе, җылылык, газ һәм су җитештерү һәм бүлү:

1) «Яр Чаллы җылылык электр үзәгендә 236 МВт куәтле пар-газ җайланмасын (ПГҖ) төзү («Татэнерго» АҖ, Яр Чаллы шәһәре);

2) «Б.Крыловка урамы һәм Краснококшайская урамы киселешендә ТК11-5/10 дән алып УТ-4кә кадәр участокта 11 нче магистраль җылылык үткәргеч төзү» («Татэнерго» АҖ, Казан шәһәре);

3) «КТЭЦ-1дән «Горки» котельныена кадәр 5 нче магистраль җылылык үткәргеч төзү» («Татэнерго» АҖ, Казан шәһәре);

4) «Җылылык энергиясен кулланучыларны исәпкә алу җиһазлары белән элемтә оештыру» («Татэнерго» АҖ, Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре, Түбән Кама шәһәре, Зәй шәһәре);

5) «Казаньоргсинтез» ГАҖ өчен пар-газ җайланмасын (ПГҖ) төзү – 250 («Казаньоргсинтез» ГАҖ, Казан шәһәре);

6) «220 кВлы Бегишево – Чистай-220 ҺЛ төзү» («Сетевая компания» АҖ, Чистай, Аксубай, Спас, Әлки, Нурлат, Алексеевск, Яңа Чишмә муниципаль районнары).

8. Агач эшкәртү һәм агачтан эшләнмәләр җитештерү:

«Өстәмә җитештерү линияләре монтажы: декоратив панельләр җитештерү буенча яссы ламинациянең 2 нче линиясе, импрегнирование буенча 3 нче линия,

меламин пресслауның 4 нче линиясе («КАСТАМОНУ ИНТЕГРЕЙТЕД ВУД ИНДАСТРИ» ҖЧҖ, Алабуга муниципаль районы).

9. Башка проектлар:

1) «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын перспективалы үстерү, шул исәптән III чиратны төзү («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ, Алабуга, Түбән Кама, Менделеевск муниципаль районнары, Казан шәһәре)

2) «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасын перспективалы үстерү («Иннополис» махсус икътисадый зонасы» АҖ, Казан шәһәре, Югары Ослан, Лаеш муниципаль районнары);

3) «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә «Яшел Үзән» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын булдыру (В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Зәй муниципаль районы);

4) «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә «Яшел Үзән-2» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын булдыру» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

5) «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә «Северные ворота» индустриаль паркын төзү («Казаньоргсинтез» ГАҖ, «Северные ворота» АҖ, Казан шәһәре);

6) «Татарстан Республикасының Түбән Кама һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә «Этилен-600» индустриаль паркын төзү («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ, Түбән Кама һәм Тукай муниципаль районнары);

7) «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә «Аммоний» индустриаль паркын төзү («Аммоний» АҖ, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ, Менделеевск муниципаль районы);

8) «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге» индустриаль (сәнәгать) паркын үстерү («Альянс» идарәче компаниясе ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

9) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә, 16:24:150301:1937 җир кишәрлегендә логистика технопаркы, 2 нче корпус («ИнПарк-Казань» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

10) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә, 16:24:150301:1937 җир кишәрлегендә логистика технопаркы, 3 нче корпус («ИнПарк-Казань» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

11) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә, 16:24:150301:1937 җир кишәрлегендә логистика технопаркы, 4 нче корпус («ИнПарк-Казань» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

12) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә, 16:24:150301:1937 җир кишәрлегендә логистика технопаркы, 5 нче корпус («ИнПарк-Казань» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

13) «АБСОЛЮТ» җитештерү паркы («АБСОЛЮТ» ҖЧҖ, Биектау муниципаль районы);

14) «Химград» технополисы территориясендә индустриаль парк булдыру («Тасма-Инвест-Торг» ҖЧҖ), 4 этап («Тасма-Инвест-Торг» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

15) «Олимп» сәнәгать технопаркы («Мастер» КИП» АҖ, Яр Чаллы шәһәре»);

16) «Техногород» индустриаль паркы» («Мастер» КИП» АҖ, Яр Чаллы шәһәре);

17) «Казан вертолет заводы» АҖ базасында «Россия вертолетлары» холдингының бердәм демонстрация-уку үзәген булдыру («Казан вертолет заводы» АҖ, Казан шәһәре);

18) «Барс аяк киемнәре компаниясе» ҖЧҖнең җитештерү куәтләрен арттыру («Барс аяк киемнәре компаниясе» ҖЧҖ, Чистай шәһәре);

19) «Новая земля» иммерсив паркы» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Бөгелмә муниципаль районы);

20) «Әлмәт шәһәрендә концертлар залы» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Әлмәт муниципаль районы);

21) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында «Нәфис Косметикс» АҖнең склад комплексын төзү (АҖ «Нәфис Косметикс», Зеленодольск муниципаль районы);

22) «Химград» технополисының җитештерү инфраструктурасын киңәйтү» («Химград» АҖ, Казан шәһәре);

23) «Казань марина» туристлык территориясен булдыру» («Туризм.РФ Татарстан Республикасы» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

24) «Зеленодольск термалары» терма комплексларын төзү («Городские Термы» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

25) «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә 50 мең кешегә исәпләнгән «Үзәк парк» микрорайонын һәм заманча медицина үзәген (хастаханәләр) булдыру» («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ, Алабуга муниципаль районы);

26) «Казан шәһәренең Вахитов районында премиаль дәрәҗәдәге кунакханә комплексы» («АМ Групп» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

27) «Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларны күпләп бүлү үзәге («Зеленодольск шәһәренең 4 нче күпләп бүлү үзәге» ҖЧҖ, Зеленодольск шәһәре);

28) «Күпфункцияле бина – Татарстан Республикасы Зеленодольск районында бүлү үзәге («Татьяна» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

29) технопарклар, индустриаль (сәнәгать) парклар, инновацион фәнни-технологик үзәкләр территорияләрендә югарыда күрсәтелмәгән, гамәлгә ашырыла торган һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

30) Татарстан Республикасының монопрофильле торак пунктларын үстерүнең комплекслы инвестицияләү планнарына кергән, югарыда күрсәтелмәгән инвестиция проектлары;

31) үсеше алга киткән территорияләрдә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган, югарыда күрсәтелмәгән инвестиция проектлары;

32) сатулар үткәрмичә, җир кишәрлекләрен арендага биреп гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган масштаблы инвестиция проектлары;

33) капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзеп, гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

34) бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдында Татарстан Республикасы бурычларын каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә янга кала торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы Татарстан Республикасы тарафыннан инфраструктура обектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиеш булган инвестиция проектлары;

35) югарыда күрсәтелмәгән, дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүләр һәм концессия килешүләре төзеп гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

36) «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналары территорияләрендә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

37) Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге территориясендә гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган инвестиция проектлары.

II. Салым ташламалары рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтеп гамәлгә ашыруга хупланган өстенлекле инвестиция проектлары:

1. Авыл хуҗалыгы:

«Биосфера-Фиш» балык үрчетү комплексы (3 нче чират)» («Биосфера-Фиш» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы).

2. Азык-төлек продуктлары җитештерү:

«6 000 тонна куәтле салат бинасын төзү» («Таткрахмалпатока» АҖ, Югары Ослан муниципаль районы).

3. Химия производствосы:

«Казаньоргсинтез» ГАҖнең түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү заводының «В» реакторын реконструкцияләү» («Казаньоргсинтез» ГАҖ, Казан шәһәре).

4. Электр энергиясе, җылылык, газ һәм су җитештерү һәм бүлү:

«Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖнең пар-газ җайланмасын – җылылык электр станциясен (ПГҖ-ҖЭС) төзү» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, Түбән Кама шәһәре).

5. Башка проектлар:

1) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә, 16:24:000000:3507 җир кишәрлегендә логистика технопаркы, 1 нче корпус («ИнПарк-Казань» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

2) «Дружба» индустриаль-логистика паркы – I чират» («ПОТОК» ИЛП» МТ ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы).